ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.09.2023 Олы Кайбыч ав. № 394

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 17апрелендәге 151 номерлы карары белән расланган Кайбыч муниципаль районы территориясендә сугыш һәм гадәттән тыш хәлләр вакытында оешмалар (предприятиеләр, учреждениеләр) эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы оешмаларының, предприятиеләренең һәм учреждениеләренең сугыш һәм гадәттән тыш хәлләр вакытында эшләвен арттыру чараларын үтәүне планлаштыру һәм контрольдә тотуны оештыру эшен алга таба камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 17апрелендәге 151 номерлы карары белән расланган Кайбыч муниципаль районы территориясендә сугыш һәм гадәттән тыш хәлләр вакытында оешмалар (предприятиеләр, учреждениеләр) эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясе составына кушымтада бирелгән яңа редакциядә каралганча үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
_____________ ___ номерлы
карарына кушымта

## Кайбыч муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар (предприятиеләр, учреждениеләр) эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясе составы

| | | |
|---|---|---|
| Комиссия рәисе | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары | Заһидуллина Эльвира Хәсбәтулла кызы |
| Комиссия рәисе урынбасары | - Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе дәүләт янгынга каршы хезмәте федераль янгынга каршы идарәсенең 8 янгыннан саклану отрядының 11 янгыннан саклану часте башлыгы (килешү буенча) | Ибраһимов Дамир Рәшит улы |
| Комиссия секретаре | - Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлек башлыгы | Закиров Рәмис Илдус улы |
| Комиссия әгъзалары: | | |
| Социаль өлкә эшчәнлеге тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе | - Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары | Петухова Фәния Фәрит кызы |
| Агросәнәгать комплексы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча төркем җитәкчесе | - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Кайбыч муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) | Камалетдинов Радик Мәҗит улы |
| Ягулык-энергетика комплексының һәм сәнәгать җитештерүенең тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе | - Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары | Сәлахов Булат Ринат улы |

| | | |
|---|---|---|
| Транспорт системасы һәм торак-коммуналь хуҗалык эшчәнлеге тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе | - Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы | Гайнуллина Юлия Викторовна |
| Идарә, элемтә, хәбәр итү системаларының тотрыклылыгын арттыру буенча төркем җитәкчесе | - «Таттелеком» ГАҖнең Кайбыч район электр элемтәсе төене башлыгы (килешү буенча) | Канашов Игорь Геннадьевич |